**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**Сарман авыл җирлеге**

**423350 Сарман авылы, Ленин ур., 28**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sarman-SP @ rambler.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 28**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sarman-SP @ rambler.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
29 декабрь 2023 г. № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2021 елның 6 маендагы 5 номерлы карары, «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законы, Сарман авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар иттем:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Сарман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;
- гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 2024 елның 12 январеньдэ 14 сәгатьтә;
- үткәрелү урыны-кино учреждениесе бинасындагы конференцзал (адресы: Сарман авылы, Ленин урамы, 28);
– фикер алышу мәсьәләсе буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр,Сарман авылы, Куйбышев урамы, 31А, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәре 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр).

3. Сарман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;
- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http//sarmanovo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөклим.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Хөснуллин